РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» декабрь 2022г. г. Альметьевск № 182

Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан авыл җирлекләренә шәһәр төзелеше эшчәнлеге елкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер елешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 елеше нигезендә, «Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Әлмәт муниципаль районы территориясендәге җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләр тапшыру (кабул итү) турында килешүләр тезү тәртибе турында» Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары белән,

Әлмәт муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан Габдрахман, Аппак, Әлмәт, Бишмунча, Бута, Борискино, Баграж-Никольский, Васильевка, Югары Акташ, Югары Мактама, Елховой, Ерсубайкино, Кәләй, Колшәрип, Кама-Исмәгыйль, Кичү, Кичүчат, Клементейкино, Кузайкино, Урман-Кәләй, Миңлебай, Мәмәт, Түбән Абдул, Яңа Кәшер, Яңа Нәдер, Яңа Никольский, Яңа Троицкий, Рус Акташы, Иске Михайловка, Сәрән, Селәй, Иске Суркино, Тайсуган, Ямаши, Ямаш авыл җирлекләренә, авыл җирлекләре Советы белән расланган, Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен тезү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү елешендә «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер елешен гамәлгә ашыруны тапшырырга.

2. Әлмәт муниципаль районы Советына авыл җирлекләре Советлары белән аларның әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешүләр тезергә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә тиешле җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәкъдим итәргә:

- җирлекләр бюджетларыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертларны бүлү методикалары һәм (яисә) бирү тәртибе нигезендә

бюджетара трансфертларның күләмен билгеләргә;

- Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән авыл җирлекләре Советларына карауга җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы 2021 елның 28 сентябрендәге 81 номерлы «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан авыл җирлекләренә шәһәр тезелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында» карарлары, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы 2021 елның 16 декабрендәге 108 номерлы «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан авыл җирлекләренә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында» карарлары,Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы 2021 елның 16 декабрендәге 109 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы 2021 елның 28 сентябрендәге 81 номерлы «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан авыл җирлекләренә шәһәр тезелеше эшчәнлеге елкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре елешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында»гы карына үзгәрешләр кертү турындагы карарларын гамәлдән чыгарырга.

6. Әлеге карарны «Альметьевский вестник»» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз кеченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча (Грушин А.И.), икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча (Минһаҗев И.М.) даими комиссияләренә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы — Т.Д. Нагуманов

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль район
Советының 2022 елның
12 декабрендәге 182 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ______ авыл Советына шәһәр тезелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешү

«___» _________ 2023 ел Әлмәт шәһәре

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче район Башлыгы ___________ йезендә, бер яктан, алга таба «Район Советы» дип аталучы, һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының _____________ авыл Советы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче, алга таба «_________________ авыл Советы» дип аталучы _____________ башлыгы йезендә, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучы түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне тезеделәр:

1. Килешү предметы

Әлеге Килешүнең предметы булып, район Советы тарафыннан _____________ авыл Советына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә муниципаль район бюджетыннан тиешле җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән шәһәр тезелеше эшчәнлеге елкәсендә,______________ авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне раслау өлешендә , ____________ авыл җирлеге Советы карары белән расланган, җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру тора.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Район Советы _______________авыл Советына тапшыра:

- әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары һәм матди ресурслар (алга таба - вәкаләтләр);

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен кирәкле мәгълүмат.

2.2. _________________ район Советы хокуклы:

- әлеге Килешүнең 5.1-5.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә авыл Советының бирелгән финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан максатчан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашырырга.

2.3. Авыл Советы бурычлы:

- кануннар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә, бары тик вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга гына;

- район Советына вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен тапшырыла торган хисаплар, шулай ук Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүматларны бирергә.

2.4. Авыл Советы хокуклы:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен район Советы тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын һәм матди ресурсларны алырга һәм кулланырга;

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен кирәкле мәгълүматны район Советыннан соратып алырга;

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс акчаларыннан өстәмә рәвештә файдаланырга.

3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен бирелә торган финанс чаралары күләме Әлмәт муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карары белән билгеләнә.

Яклар ел саен тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен әлеге килешүгә кушымта нигезендә билгелиләр.

3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары квартал саен тигез елешләр белән күчерелә.

3.4. Авыл Советы финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар район Советы җирлеге бюджетына ун кен эчендә кайтарылырга тиеш.

4. Матди ресурсларны тапшыру тәртибе

4.1«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 елешенең 5 пункты нигезендә кабул ителгән муниципаль районның вәкиллекле органы карары нигезендә____ авыл Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен әлеге Килешүне имзалаган кеннән утыз кен эчендә кабул итә, ә район Советы муниципаль мелкәтне түләүсез вакытлы файдалану шартнамәсе нигезендә тапшыра.

4.2. Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән түләүсез файдалану шартнамәсе кичектергесез була һәм әлеге Килешүнең гамәлдә булу чорына төзелә.

4.3. Әлеге Килешүнең 4.1 пункты нигезендә тапшырылган матди ресурслардан файдалану тәртибе түләүсез файдалану шартнамәсе белән билгеләнә һәм аның меһим шарты булып тора.

5. Вәкаләтләрне үтәүне тикшереп тору

5.1. Район Советы вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, ____ авыл Советыннан тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала. ____ авыл Советы район Советы соратып алынган мәгълүмат бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга кереп йөрүен тәэмин итәргә тиеш.

5.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе район Советының хокукый актлары белән билгеләнә.

5.3. Тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны тотуны тикшереп тору Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы һәм район Советы тарафыннан, шул исәптән ________авыл Советы, район Советы таләбе буенча гамәлгә ашырыла.

6. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

6.1. Әлеге Килешү рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз кеченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә ђулуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6.3. Якларның берсе дә аны өзү турында әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 кеннән дә соңга калмыйча белдермәсә, Килешү чираттагы календарь елга озайтылган дип санала.

7. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

7.1. Әлеге Килешүнең гамәле вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- яклар килешүе буенча;
- бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

7.2. Әлеге Килешүне езү турында хәбәрнамә башка Якка язмача рәвештә, аның гамәлдә булу датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

7.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, ________________ авыл Советы вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларың һәм матди ресурсларны район Советына кире кайтара.

8. Якларның җаваплыгы

8.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

8.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як икенче Якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф сала.

8.3. Штраф түләү Яклар әлеге Килешү буенча бурычларны алга таба үтәүдән азат итми.

9. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сейләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сейләшүләр уздыру яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мемкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

10. Йомгаклау нигезләмәләре

10.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм естәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә естәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Килешү Якларның һәркайсы өчен бере буенча тигез юридик кечкә ия ике нөсхәдә тезелгән.

11. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгы | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы _________ авыл Советы башлыгы |
| ________________________________ | ____________________________ |

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

•СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА•

2023 елның ______
килешүгә кушымта

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләр буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме

| № п/п | Чыгымнар статьясы | Сумма (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм авыл җирлегендә төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне раслау өлешендә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге елкәсендәге аерым мәсьәләләр буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ____авыл Советы тарафыннан, муниципаль район бюджетыннан____ авыл бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына__________ авыл җирлеге Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә башкарыла | 0 |
| Барлыгы | | 0 |